РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
СОВЕТ
Салманского сельского
поселения Алькеевского
муниципального района

ТАТАРСТАНРЕСПУБЛИКАСЫ
Әлкимуниципаль районы
Салманавылҗирлеге
СОВЕТЫ

Адрес:422874, Республика
Татарстан, Алькеевский район,
с.Салманы,
ул. Молодёжная, д.12.
тел: 8 (84346) 72-2-38

Адресы:422874,Татарстан
Республикасы, Әлки районы,
Салманавылы,
Яшьләрур., 12.
тел.: 8 (84346) 72-2-38

**РЕШЕНИЕ** **Салман ав.** **КАРАР**

2025 елның " 25 " июне № 104

Салман авыл җирлеге Советы 01.12.2021 елгы № 16 «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау хакында" карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 19 пункты, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Салман авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Салман авыл җирлеге Советының 01.12.2021 елгы №16 (үзг. 04.02.2022 ел № 22, 21.06.2022 ел №31, 13.12.2023 ел № 69, 26.06.2024 ел № 82, 24.12.2024 ел № 92) карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4.23 нче пунктның 1 нче подпункты яңа редакциядә бәян итәргә:

1) контроль (күзәтчелек) чарасы актын рәсмиләштергәннән соң контрольдә тотылучы затка мәҗбүри таләпләрне ачыкланган бозуларны бетерү турында, аларны бетерүнең акыллы срокларын, шулай ук Контроль төре турындагы Федераль законда каралган башка чараларны күрсәтеп, күрсәтмә бирергә.

3 нче кушымтаның 2 пунктындагы 6 нчы искәрмәне үз көчен югалткан дип танырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында (https://alkeevskiy.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Салман авыл җирлеге
Башлыгы

И.В. Юсупов.